# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2021 елның 21 апреле №35

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләренә кермәгән, Бишнә авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бишнә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән, Бишнә авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 2.3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**